ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.02.2020 Олы Кайбыч ав. № 89

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кайбыч муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары исемлеген раслау хакында» 2019 елның 17 декабрендәге 550 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Балигъ булмаганнарга тәмәкесез никотинлы, никотинны илтеп җиткерүнең электрон системаларын сатуны тыю һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 25 декабрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 550 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген Татарстан Республикасы административ хокук бозулар турында Кодексының 2.1 (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органының, башка дәүләт органының, җирле үзидарә органының, предприятиенең, учреждениенең, башка оешманың элмә такталарда урнаштырылырга тиешле үз исеме турында белешмәләре һәм элмә такталарда күрсәтелә торган башка мәгълүматны күрсәткәндә Татарстан Республикасының телләр турында законнарын бозуга карата),), 2.4-2.8, 2.12-14, 2.15, 2.16, 3.3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14-3.3.17, 4.4.5, 5, 2.6 (Кайбыч муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль ташуларга карата) статьяларында каралганча билгеләргә. (Кушымта).»;

карар кушымтасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| 2.16 статья. Балигъ булмаганнарга тәмәке булмаган никотинлы продукцияне, никотинны илтеп җиткерүнең электрон системаларын сатуны тыюны бозу, шулай ук балигъ булмаганнарны тәмәке булмаган никотинлы продукцияне куллануга җәлеп итү | - Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисадый мәсьәләләр);<br>- Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлеге башлыгы;<br>- Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлегенең баш белгече. |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://kaybici.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Н.Макаров